


**КҮПНЕ КӨТКӘНДӘ**
Быелгы уңыш өметне акладымы?
> 2



**ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ**
«Подъезд янында ирләр гәпләшеп тора. Алар янына килеп җитүгә...»
> 3




**ТЕЛӘК КИРӘК!**
Яңа Мәрҗани һәм Барудиларны укыта торган мәдрәсәгә ничек булышырга?
> 3



**ГАИЛӘ КӨЧЕ**
«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты
> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 137 (29104) | Чәршәмбе | 20 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131


# КОЯШ КЕСӘНЕ ТИШМИ



Эльвира ВӘЛИЕВА

Көн кадагында

**Көннәр суытканны көтәсе юк. Татарстанның унөч районында җылылык бирү сезоны башланган инде. Бу хакта төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин әйтте. Ул, салкыннар башлангач, коммуналь хезмәтләр өчен түләү артачагын да искә төшерде. Кыш кесәгә сукмасмы?**



Илдар Мөхәммәтҗанов

Республиканың ТКХ объектлары җылылык бирү сезонына 99,9 процентка әзер. Бу хакта Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта хәбәр иттеләр. Министр Марат Айзатуллин сүзләренә караганда, җылылык бирүгә әзерлек коммуналь инфраструктураны яңарту федераль программасы кысасында алып барыла.

– Быел Әгерҗе, Зәй, шулай ук Казан һәм Чаллыдагы җылылык бирү һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрендә 27 чара тәгаенләштерелгән, – диде министр.

Сүз уңаеннан, быелның язында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә узган киңәшмәләрнең берсендә Әгерҗедә коммуналь инфраструктураның хәленә аерым тукталдылар. Мактап түгел. Ул вакытта Рөстәм Миңнеханов «Татэнерго» оешмасы генераль директоры Рәүзил Хаҗиевка якташларына ярдәм итәргә кирәклеген әйтте. Соңгы мәгълүматларга караганда, районда әлеге тармакта зур ремонт, яңарту эшләре башкарганнар. Әгерҗе – быелгы җылылык бирү сезонын инде башлап өлгергән унөч районның берсе.

– Төрле имеш-мимешләргә дә карамастан, Зәй ГРЭСы да җылылык бирү сезонына тулысынча әзер, – дип белдерде Хөкүмәт йортында узган чарада Рәүзил Хаҗиев.

Билгеле булганча, җылылык бирү сезоны урамдагы һава температурасы биш көн дәвамында тәүлегенә уртача 8 градус җылыдан түбән торса башланырга тиеш. Дөрес, әлегә көз җәйдән кимен куймый. Бу атнада, мәсәлән, республикада урыны белән 25 градуска кадәр җылы булырга мөмкин, дип фаразлый синоптиклар. Төнлә исә температура 8–10 градус җылы булачак, дип көтелә. Ә тәүлеклек уртача температураны билгеләү өчен көндезге һәм төнге күрсәткечләрне кушып, шуларны икегә бүләргә кирәк. Тик исәп-хисап белән баш катырырга ашыкмагыз, торбаларны салкыннарны башлануын көтеп тормыйча да җылыта башларга мөмкиннәр.

– Муниципаль берәмлекләр үзләре, һава температурасына карамастан, җылылык бирү сезонын башлау турында карар кабул итә ала. Иң беренче чиратта балалар бакчалары, мәктәп, хастаханәләр кебек социаль объектлар тәэмин ителәчәк. Бүген республиканың унөч районында җылылык бирү сезоны башланды, – диде Марат Айзатуллин.

Бер рәхәтнең бер кыены була, дигәндәй, торбалар кайнарлану белән, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазьләре дә кыйммәтләнәчәк. Бу хакта министр да әйтте.

– Җылылык сентябрь аенда бирелә башлаган очракта, октябрьдә алган «счет-фактура» кәгазендә җылылык өчен түләү турында аерым пункт барлыкка киләчәк. Узган айда тотылган энергия өчен исәп-хисап ясалачак. Гомуми йорт исәпләгечләре булмаган торакта яшәүчеләр исә җылылык бирү сезоны дәвам иткән сигез айны исәпкә алып, алдан билгеләнгән нормативлар буенча түләячәк, – диде Марат Айзатуллин.

Министр мичкә күбрәк яккан саен, өстәп түләргә туры килүен дә искә төшерде.

– Җылылык энергиясенә бәйле чыгымнар һава температурасына турыдан-туры бәйле. Кагыйдә буларак, җылылык өчен иң зур түләүләр гыйнвар – февраль айларында килә, – диде ул.

Дөрес, министр Татарстанда яшәүчеләрне алдан ук тынычландырып та куйды:

– Быелның 1 июленнән кулланучылар өчен коммуналь хезмәтләр, шул исәптән җылылык өчен тарифлар үзгәрмәде. Чираттагы индексацияләү 2024 елның 1 июленнән генә булачак, – диде Марат Айзатуллин.

**Быел җылылык бирү сезоны башланган районнар**
Әгерҗе ▶ Аксубай ▶ Апас ▶ Арча ▶ Баулы ▶ Буа ▶ Югары Ослан ▶ Биектау ▶ Кама Тамагы ▶ Мөслим ▶ Яңа Чишмә ▶ Чирмешән ▶ Ютазы

Хәтерләсәгез, соңгы тапкыр коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр ил күләмендә узган елның 1 декабрендә артты. Россия Хөкүмәте карары нигезендә былтыр тарифлар бер ел эчендә ике тапкыр (ут-су, җылылыкка бәяләр гадәттә елга бер тапкыр үсә) күтәрелде. Алдагы ел белән чагыштырганда, республиканың кайбер шәһәр һәм районнарында яшәүчеләрнең ут һәм суга киткән чыгымнары 20 процентка кадәр артты. Шуңа күрә дә былтыр кыш уртасында килеп төшкән коммуналь түләү кәгазьләре халык арасында зур шау-шу уятты. Рөстәм Миңнеханов аңлату эшләре оештырырга да кушты хәтта. Быел исә коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр былтыргыдан да зуррак булмаячак, дип өметләнәсе генә кала. Бөтендөнья метеорология оешмасы белгечләре Россиядә быелгы кышны гадәттән тыш җылы булачак дип фаразлаган инде әнә. Әйтүләренә караганда, кышның беренче ике ае нормадан 4–5 градуска җылырак булачак. Аның каравы күп итеп кар һәм бозлы яңгырлар вәгъдә иткәннәр. Коммуналь хезмәткәрләр генә чыдасын.

## Кушылу көне

Россия Дәүләт Думасы 30 сентябрьне Донецк, Луганск халык республикаларының, Запорожье һәм Херсон өлкәләренең Россиягә кушылу көне буларак билгеләү турында закон проектын беренче укылышта кабул иткән. Президент Владимир Путин әлеге документны Дәүләт Думасына 12 сентябрьдә керткән иде.

Исегезгә төшерәбез: узган елның 23–27 сентябрендә яңа төбәкләрне Россия составына кертү мәсьәләсе буенча референдумнар узды. Запорожье өлкәсендә – сайлаучыларның 93,11 проценты, Херсон өлкәсендә – 87,05, Луганск Халык Республикасында – 98,42, Донецк Халык Республикасында сайлаучыларның 99,23 проценты Россиягә керүне хуплап тавыш бирде. Ә инде 30 сентябрьдә Мәскәү Кремлендә яңа территорияләрне Россия составына кертү турында килешүләрне имзалау тантанасы узды. Документларны Владимир Путин һәм кушылган төбәкләр башлыклары имзалады.

## *Кирәкле кешеләр*

Татарстан Хөкүмәте республика оешмалары өчен кирәкле һөнәрләр исемлегенә яңаларын өстәгән. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән боерыкка кул куйган.

Шулай итеп, яңартылган исемлеккә химик анализ лаборанты, тимер һәм эретмәләр коючы, буяучы, кран машинисты, цех механигы, контроль-үлчәү приборларын көйләүче, автомат һәм ярымавтомат станоклар операторы, тимер эретүче, бораулаучы, слесарь, токарь кебек һөнәрләр кертелгән.

## Ярышу өчен тырышу

Киләсе елда Парижда узачак Олимпия уеннарына Россия спортчылары кертелсә, бездән анда 180 кеше чыгыш ясый алачак. Россия спорт министры Олег Матыцин әйтүенчә, спортчыларның квалификациясе мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнгән сан бу. «Командаларның катнаша алмаячагын аңлыйбыз. Бу – максималь сан. Гәрчә хәлләр көн саен үзгәреп торса да. Тик, кызганычка, яхшы якка түгелдер, мөгаен», – дигән министр.

Әлегә Халыкара Олимпия комитеты Россия, Белоруссия спортчыларын Парижда узачак уеннарга кертү турында карар чыгармады. Оешманың гамәлдәге кагыйдәләре буенча, ике ил спортчылары халыкара турнирларда нейтраль статуста һәм бары шәхси ярышларда гына чыгыш ясый ала.

Яңалык

## Кәгазьдәгесе югалмый

**Россия Президенты Владимир Путин цифрлы паспорт турында указны имзалады. Шәхесне раслау хәзер тагын да җиңеләя: интернет һәм телефоның гына булсын!**

Дәүләт башлыгы указында язылганча, Россиядә яшәүчеләр мобиль кушымта (бу очракта «Госуслуги») кулланып, таләп ителгән җирдә үзенең шәхесен раслата ала. Әмма әлеге «таләп ителгән» урыннарны ил Хөкүмәте үзе билгели. Владимир Путин өч ай эчендә мобиль кушымта аша күрсәтелергә мөмкин булган мәгълүматлар тупланган документлар исемлеген билгеләргә кушты. Аны куллану һәм реестрны алып бару тәртибен шулай ук Министрлар Кабинеты расларга тиеш. Шуңа күрә электрон паспортны ничек кулланасы әлегә билгеле түгел. Гади итеп әйткәндә, цифрлы паспорт үз эченә паспортны гына түгел, башка төр документларны (әйтик, машина йөртү таныклыгы) да алачак.

**Сан**

2020 елда Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре электрон паспорт турында сораштыру үткәргән иде. Сораштыруда катнашучыларның 9 проценты, аның уңай яклары турында сөйләгәндә, паспортны урлап яисә югалтып булмый, дип белдергән. 6 проценты исә, кәгазь паспорт кебек, үзең белән йөртергә кирәк түгел, дигән. 4 проценты, андый паспорт пычранмый, ертылмый, дип әйткән. Шулай ук илдә яшәүчеләрнең һәр дүртенчесе, андый паспортның берниндә дә өстенлеге юк, дигән фикердә.




ru.freepik.com


Россиянең Цифрлаштыру министрлыгы искәрткәнчә, электрон паспорт кәгазь документны алмаштырмаячак. Теләге булган кешеләр гадәтләнгән кәгазь паспорт белән йөри алачак. Электрон паспортны рәсмиләштерү ирекле.

Министрлык мондый паспортның якынча ничек эшләвен дә аңлаткан иде. Барысы да бик гади: телефонга паспортның фотосурәтләрен кертә, соңрак QR-код чыкканын көтәсе. Шушы кодны паспорт урынына кулланырга мөмкин дә инде.

Шунысы да бар: кайбер белгечләр, цифрлы паспортларның гамәлгә керүе базадан шәхси мәгълүматны урлау очраклары артуга китерергә мөмкин, ди.

Сүз уңаеннан, электрон паспорт төшенчәсе яңалык түгел. Казахстанда, мәсәлән, шәхесне раслаучы махсус чип-таныклык 2008 елда ук кертелгән иде. Эстониядә ID-карта дигән электрон документ гамәлдә. Германиядә дә шундый ук ID-карта бирәләр.

Сүзгә-сүз



**Владимир ПУТИН, Россия Президенты:**

Россия икътисадын торгызу этабы тәмамланды дип әйтергә була. Без моңарчы күрелмәгән тышкы басымга, санкцияләр һөҗүменә каршы тора алдык. Россиянең тулай эчке продукты 2021 елгы күрсәткеченә чыкты. Безгә алга таба да тотрыклы һәм озак вакытлы үсеш өчен шартлар тудыру мөһим.

**(Федераль бюджет формалаштыру мәсьәләләре буенча киңәшмәдән)**

## РОССИЯДӘ – КӨЗГЕ ЯЛ

**SuperJob хезмәте Россиядә яшәүчеләр арасында көзге ял өчен иң популяр төбәк һәм шәһәрләрне ачыклаган.**

1 >> Санкт-Петербург
2 >> Краснодар крае
3 >> Төньяк Кавказ
4 >> Казан
5 >> Алтай
6 >> Кырым





## *Муллыктан өлеш*

Татарстанда гошер сәдакасын җыю дәвам итә. Билгеле булганча, Татарстан Диния нәзарәте гошер көне дип агымдагы елның 23 сентябрен игълан итте. Гошер көне Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә. Һәр елдагыча, мөхтәсибәтләрдәге мәчетләр гошер сәдакасы итеп җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул итә. Соңрак азык-төлекне аз керемле, мохтаҗ кешеләргә тапшыру оештырылачак. Казанда гошерне нәзарәт карамагындагы «Зәкят» хәйрия фонды кабул итә һәм тарата.

Саннарга күз салсак, 2017 елда – 160 тонна, 2018 елда – 600 тонна, 2019 елда – 1109,5, 2020 елда – 1000 тоннага якын, 2021 елда – 577,33 тонна, 2022 елда 1377,34 тонна гошер сәдакасы җыеп таратылган.



dumrt.ru